**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАМСКО-УСТЬИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

ул. Калинина, д.31,
пгт. Камское Устье, 422820

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАМА ТАМАГЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Калинин урамы, 31 йорт,
штп. Кама Тамагы, 422820

тел.: (884377) 2-18-85, факс: 2-20-70, e-mail: Kamuste.Ispolkom@tatar.ru, http://kamskoye-ustye.tatarstan.ru.

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

06.05.2022 № 592

Кама Тамагы муниципаль районы белем бирү оешмаларында танылган сәләтләр күрсәткән укучыларны һәм аларның остазларын кызыксындыру чаралары турында Нигезләмәне раслау хакында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 77 статьясындагы 4 пункты нигезендә, Кама Тамагы муниципаль районы мәгариф оешмаларында фән олимпиадаларында, фәнни-гамәли конференцияләрдә, конкурсларда сәләтләрен күрсәткән укучыларны бүләкләү максатларында, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Кама Тамагы муниципаль районы белем бирү оешмаларында танылган сәләтләр күрсәткән укучыларны һәм аларның остазларын кызыксындыру чаралары турында Нигезләмәне расларга ( Кушымта итеп бирелә)

2. Кама Тамагы муниципаль районы «Мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесенә Кама Тамагы муниципаль районы белем бирү оешмалары укучыларын һәм аларның остазларын расланган сметалар нигезендә матди кызыксындыру өчен акча бүлеп бирүне тәкъдим итәргә. Чыгымнарны Кама Тамагы муниципаль районы «Мәгариф идарәсе» МКУ бюджет язмасында каралган ассигнованиеләр чикләрендә, шулай ук башка чыганаклар хисабына тормышка ашырырга.

3. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының «Кама Тамагы муниципаль районы белем бирү оешмаларында танылган сәләтләр күрсәткән укучыларны һәм аларның остазларын кызыксындыру

чаралары турында Нигезләмәне раслау турында» 2017 елның 29 маендагы, 548 номерлы карары үз көчен югалткан дип санарга

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (игътисад үсеше буенча) М.Х. Хәбибуллоvага йөкләргә.

Җитәкче Р.М. ЗаҺидуллин

Кама Тамагы муниципаль районы
Башкарма комитетының 2002 елның 6
маендагы 592 номерлы карарына
1 нче кушымта.

Кама Тамагы муниципаль районы белем бирү оешмаларында танылган сәләтләр күрсәткән укучыларны һәм аларның остазларын кызыксындыру чаралары турында
НИГЕЗЛӘМӘ

Кама Тамагы муниципаль районы белем бирү оешмалары укучыларын, шулай ук аларның остазларын кызыксындыру чаралары турында әлеге нигезләмә (алга таба - нигезләмә) ст. 4 п. нигезендә эшләнгән 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә мәгариф турында» гы Федераль закон, Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Кама Тамагы муниципаль районының башка норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән Министрлыгы һәм Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы боерыклары нигезендә турыдан туры үткәрелгән фән олимпиадаларында, фәнни-гамәли конференцияләрдә, конкурсларда сәләтләрен күрсәткән муниципаль белем бирү оешмалары укучыларын бүләкләү максатларында эшләнгән.

.Нигезләмә Кама Тамагы муниципаль районы белем бирү оешмаларында танылган сәләтләр күрсәткән укучыларны һәм аларның остазларын кызыксындыру чаралары тәртибен билгели (акчалата премияләр тапшыру тәртибе).

Акчалата премия түбәндәге күләмдә тапшырыла:

- гомуми белем бирү предметлары буенча Бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасының йомгаклау этабында, шулай ук халыкара олимпиадаларда, бөтенроссия конкурслары һәм ярышларда җиңүчеләргә 10 000 сум күләмендә ;

-гомуми белем бирү предметлары буенча Бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасының йомгаклау этабы, шулай ук халыкара олимпиадалар, Бөтенроссия конкурслары һәм ярышлары призерларына 5 000 сум күләмендә;

- «Ел укучысы», «Иң яхшы вожатый»бәйгеләренең региональ этабында җиңүчегә 3000 сум күләмендә;

-«Ел укучысы», «Иң яхшы вожатый»бәйгеләренең региональ этабы призерларына 1500 сум күләмендә;

- гомуми белем бирү предметлары буенча Бөтенроссия олимпиадасының региональ этабы һәм республика олимпиадасының йомгаклау этабы җиңүчеләренә- 3000 сум күләмендә ;

– гомуми белем бирү предметлары буенча Бөтенроссия олимпиадасының региональ этабы һәм республика олимпиадасының йомгаклау этабы призерларына 1500 сум күләмендә ;

– рейтинг исемлегенә кергән Республика фәнни-гамәли конференцияләрендә җиңүчеләргә, призерларга (Гран-при, дипломантларга, лауреатларга) 500 сум күләмендә ;

4. Олимпиадаларда, конкурсларда, конференцияләрдә җиңгән укучылар исемлеге Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән Министрлыгы һәм Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы боерыклары нигезендә төзелә.

5. Команда ярышларында яки төркем чыгышларында җиңгән өчен акчалата бүләкләргә исемлекләр әзерләгәндә команда яки төркем өчен 1 акчалата бүләк буларак исәпкә алына.

6. Фән олимпиадаларында, фәнни-гамәли конференцияләрдә, конкурсларда сәләтләрен күрсәткән педагогик хезмәткәрләргә – остазларга акчалата премияләр түбәндәге күләмдә тапшырыла:

-гомуми белем бирү предметлары буенча Бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасының йомгаклау этабында, шулай ук халыкара олимпиадалар, конкурслар һәм ярышларда җиңүчеләрне әзерләгән педагогларга 4000 сум күләмендә акча каралган;

- гомуми белем бирү предметлары буенча Бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасының йомгаклау этабы, шулай ук халыкара олимпиадалар, конкурслар һәм ярышлар призерларын әзерләгән педагогларга 3000 сум күләмендә;

- гомуми белем бирү фәннәре буенча Бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасының республика этабында җиңүчеләрне әзерләгән педагогларга 3000 сум күләмендә.

- гомуми белем бирү фәннәре буенча Бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасының республика этабы призерларын әзерләгән педагогларга 2000 сум күләмендә.

- рейтинг исемлегенә кергән Республика фәнни-гамәли конференцияләрендә, иҗади конкурсларда җиңүчеләрне әзерләгән педагогларга 1000 сум күләмендә;

рейтинг исемлегенә кергән Республика фәнни-гамәли конференцияләре, иҗади конкурслар призерларын әзерләгән педагогларга 500 сум күләмендә;

7. Гомуми белем бирү оешмасы укучысы берничә олимпиада, конкурсларда, ярышларда җиңүче яки призер булган очракта, аңа иң яхшы нәтиҗә өчен акчалата бүләк тапшырыла

8. Акчалата премияләрне тапшыру Кама Тамагы муниципаль районының «Мәгариф идарәсе» МКУ боерыгы белән башкарыла.